ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«16» ноябрь 2023 ел «Татарстан» совхозы п № 16

«Кнәз авыл җирлегенең 2024 елга
һәм 2025 - 2026 еллар план чорына бюджет проекты
буенча Җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында ».

Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге халкының «2024 елга, 2025-2026 еллар план чорына Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге бюджеты проекты турында» гы карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законга, Кнәз авыл җирлеге Уставына, "Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында" Нигезләмә таянып

КАРАР БИРӘМ :

1. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының 2023 елның 14 ноябрендә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан ителгән «Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлегенең 2024елга һәм 2025-2026 елларның планлы чорына бюджеты турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
2. Әлеге карарны 2023 елның 17 ноябреннән дә соңга калмыйча җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Билгеләү:
3.1 халык тыңлаулары үткәрү вакыты – 28.11.2023 ел 14.00 сәгатьтә;
3.2 үткәрү вакыты – 1 көн;
3.3 үткәрү урыны – ТР, Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге, Сөвет урамы, 2 йорты (Кнәз авыл мәдәният йорты).
3.4 сораулар ,тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, Кнәз авылы, Совет урамы, 3 йорт, (эш көннәрендә-8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр) бирергә кирәк
4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге башкарма комитетына «2024 елга, 2025-2026 еллар план чорына Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге бюджеты турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Кнәз авылы
җирлеге башлыгы урынбасары
4 нче сайлау округы депутаты Ф.Ф.Хафизова

Совет КНЯЗЕВСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021601374167
Р.05-11796/09
ИНН 1639009721